РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГОРОДА КУКМОР
422110, г. Кукмор, ул. Ленина, 15

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КУКМАРА ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ
422110, Кукмара ш., Ленин ур. 15

Тел.:8(84364)2-61-88, факс:8(84364)2-63-04,e-mail:kukmor.kuk@tatar.ru,www:kukmor.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 17 феврале № 6

Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сату тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне электрон формада сатуны оештыру һәм үткәрү турында» 2012 елның 27 августындагы 860 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2012 елның 27 августындагы 860 номерлы карары) нигезендә, Кукмара шәһәр Советы карар бирде:

1. Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сату тәртибе турындагы Нигезләмәне (кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге бүлегендә урнаштырырга.

Кукмара шәһәре Мэры С. Д. Димитриев

Кукмара шәһәр Советының 2020 елның 17 февралендәге 6 номерлы карарына кушымта

# КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КУКМАРА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ МИЛКЕНДӘ БУЛГАН МУНИЦИПАЛЬ МӨЛКӘТНЕ ЭЛЕКТРОН РӘВЕШТӘ САТУНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ ҮТКӘРҮ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәре муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль мөлкәтне (алга таба – муниципаль мөлкәт, мөлкәт) мөлкәт бәясе турында тәкъдимнәр бирүнең ачык формасы белән аукцион (алга таба – аукцион) үткәрү юлы белән, махсуслаштырылган аукцион, конкурс, халык алдында (гавами) тәкъдим кертеп яисә бәясен игълан итмичә мөлкәтне электрон рәвештә сатуны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль милекне сату Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан башкарыла.

1.3 Муниципаль мөлкәтне сатканда сатучы түбәндәге функцияләрне башкара:

а) хосусыйлаштыру турында Федераль закон таләпләренең, шулай ук аның нигезендә кабул ителгән мөлкәт сатуны җайга салучы норматив хокукый актларның үтәлешен тәэмин итә;

б) сатылырга тиешле мөлкәтне билгеләнгән тәртиптә бәяләүне тәэмин итә;

в) хосусыйлаштыру турында Федераль законда билгеләнгән очракларда, мөлкәтне сатуның башлангыч бәясен, беренчел тәкъдимнең бәясен һәм халык алдында (гавами) тәкъдим кертү юлы белән мөлкәтне сатканда киметү бәясен (цена отсечения), махсуслаштырылган аукцион үткәргәндә сатуның бердәм бәясен, шулай ук «аукцион адымы» һәм «киметү адымы»н билгели;

г) электрон мәйданчык операторын җәлеп итү турында карар кабул итә, аның белән шартнамә төзи;

д) мөлкәт сатуда катнашу өчен гаризаның электрон формасын раслый;

е) электрон мәйданчык операторы белән килешү буенча гаризаларны электрон мәйданчыкта теркәү башлану һәм тәмамлану датасын, мөлкәтне сату процедурасын үткәрү датасын һәм вакытын билгели;

ж) физик һәм юридик затлар тарафыннан аукционда, конкурста, гавами тәкъдим аша мөлкәт сатуда катнашу өчен задаток кертүнең күләмен, срокларын һәм шартларын, шулай ук задаток турында шартнамәнең башка шартларын билгели;

з) РФ Хөкүмәтенең 2012 елның 27 августындагы 860 номерлы карары белән билгеләнгән очракларда, дәгъва итүчеләр белән задаток турында шартнамәләр төзи;

и) дәгъва итүчеләр тарафыннан тапшырылган документларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә һәм аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә һәм мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә булган исемлеккә туры килүен билгели;

к) хосусыйлаштыру турында Федераль законда билгеләнгән тәртиптә мөлкәт сату һәм мөлкәт сату нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәр әзерләүне, шулай ук

мәгълүматны «Интернет» челтәрендә хосусыйлаштыру турында Федераль законда, «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда һәм 2012 елның 27 августында кабул ителгән 860 нчы номерлы РФ Хөкүмәте карарында билгеләнгән таләпләр нигезендә урнаштыруны оештыра;

л) хосусыйлаштыру турында Федераль законда билгеләнгән нигезләр буенча, дәгъва итүчеләрне мөлкәтне сатуда катнашучылар (алга таба – катнашучылар) дип тану яки мөлкәтне сатуда катнашырга рөхсәт бирмәү турында беркетмә тарафыннан рәсмиләштерелә торган карар кабул итә;

м) мөлкәт сатуның җиңүчесен билгели һәм мөлкәтне сату нәтиҗәләре турында беркетмә имзалый;

н) дәгъва итүчеләр, катнашучылар һәм җиңүче белән исәп-хисап ясый;

о) җиңүче белән электрон документ формасында сату-алу шартнамәсе төзи;

п) җиңүчегә мөлкәтне тапшыруны тәэмин итә һәм аңа милек хокукы күчүгә бәйле кирәкле гамәлләрне кыла;

р) хосусыйлаштыру турында Федераль законда һәм РФ Хөкүмәтенең 2012 елның 27 августындагы 860 номерлы карары белән каралган башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

1.4. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын (алга таба – мәдәни мирас объекты) сатуны үткәргәндә, конкурста сатучы әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән функцияләрдән тыш түбәндәгеләрне башкара:

а) җиңүче тарафыннан конкурс шартларын үтәүне контрольдә тота;

б) конкурс шартларын үтәүне контрольдә тоту буенча комиссия төзи;

в) җиңүченең конкурс шартларын үтәве турында контроль комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән актны раслый.

## 2. Конкурс шартларын эшләү һәм раслау тәртибе

2.1. Конкурста муниципаль мөлкәтне сатканда, конкурс шартларын эшләүне Башкарма комитет башкара.

2.2. Мәдәни мирас объекты сатылган очракта, конкурс шартлары Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле орган һәм Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты белән килештерелергә тиеш.

2.3. Конкурс шартлары түбәндәгеләрне карарга мөмкин:

- эш урыннарының билгеле бер санын саклап калу;

- хезмәткәрләрне яңадан әзерләү һәм (яки) квалификациясен күтәрү;

- фәнни һәм (яки) фәнни-техник эшчәнлекне, халыкка социаль-мәдәни, коммуналь-көнкүреш яки транспорт хезмәте күрсәтү өчен файдаланыла торган аерым объектларның билгеләнешен үзгәртүне чикләү һәм (яисә) әлеге объектларны куллануны туктату;

- социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш объектларына карата ремонт һәм башка эшләр башкару;

- «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкярләр) турында» Федераль законның 47.6 статьясында каралган сакчылык йөкләмәсе нигезендә, ә мондый сакчылык йөкләмәсе булмаганда –

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкярләр) турында» Федераль законның 48 статьясындагы 8 пунктында каралган башка сакчылык документы нигезендә мәдәни мирас объектларын саклау эшләрен үткәрү.

Конкурс шартлары икътисади нигезләнешкә, аларны үтәү сроклары, конкурсның җиңүчесе тарафыннан мондый шартларның үтәлүен раслау тәртибенә ия булырга тиеш. Конкурс шартлары үзгәртелергә тиеш түгел.

Конкурс шартларының күрсәтелгән исемлеге тулы була.

2.4. Конкурс шартлары аны үткәрү турында мәгълүмати хәбәрдә урнаштырылырга тиеш.

3. Конкурс шартлары үтәлешен контрольдә тоту тәртибе

3.1. Конкурс шартларының үтәлеше конкурста җиңүче белән төзелгән муниципаль милекне сату-алу килешүе нигезендә Башкарма комитет тарафыннан контрольдә тотыла.

3.2. Конкурс шартлары үтәлешен нәтиҗәле контрольдә тотуны тәэмин итү өчен Башкарма комитет түбәндәгеләрне үтәргә бурычлы:

а) конкурс нәтиҗәләре буенча төзелгән мөлкәтне сату-алу шартнамәләрен исәпкә алып барырга;

б) конкурста җиңүчеләрнең мөлкәт сату-алу килешүләре белән билгеләнгән йөкләмәләрен исәпкә алу һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга;

в) конкурста җиңүчеләрдән конкурс шартларын үтәүне раслаучы хисап документларын кабул итәргә;

г) конкурс шартлары үтәлешен раслау өчен конкурста җиңүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документларны, шулай ук тикшерелә торган объектларның урнашу урынында конкурс шартларының фактта үтәлешен тикшерүне үткәрергә. Документларны тикшерү, шулай ук канәгатьләнмәслек хәлдә булган мәдәни мирас объектларына карата фактик кулланылышны тикшерү кварталга бер тапкырдан артык, әмма елына бер тапкырдан да ким үткәрелмәскә тиеш;

д) Россия Федерациясе законнарында һәм мөлкәтне сату-алу шартнамәсендә каралган тәртип бозуларны бетерүгә һәм конкурс шартларын үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә.

3.3. Конкурста җиңүченең хисап документларын тапшыру вакыты һәм формасы конкурс шартлары һәм муниципаль мөлкәтне сату-алу шартнамәсе белән, документларның кварталга бер тапкырдан да артык тапшырылмавын исәпкә алып билгеләнә.

3.4. Конкурс шартлары үтәлү вакыты чыккан көннән соң 10 эш көне эчендә, конкурста җиңүче Башкарма комитетка кирәкле барлык документлар белән бергә конкурс шартларын үтәве турында җыелма (йомгаклау) хисап җибәрә.

3.5. Башкарма комитет конкурс шартларының үтәлеше турында җыелма (йомгаклау) хисапны алганнан соң 2 ай эчендә, конкурста җиңүче тарафыннан тапшырылган җыелма (йомгаклау) хисабы нигезендә, конкурс шартларының фактик үтәлешен тикшерә.

3.6. Конкурс шартларының үтәлешен тикшерү әлеге максатлар өчен махсус төзелгән конкурс шартларын үтәүне контрольдә тоту комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

Комиссия эшенең тәртибе, аны төзү һәм оештыру Башкарма комитет күрсәтмәсе белән җайга салына.

3.7. Комиссия составына түбәндәге вәкилләр кертелә:

- Башкарма комитеттан;
- Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетыннан (килешү буенча);
- Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасыннан ( килешү буенча);
- Мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма органнан (килешү буенча), мәдәни мирас объектын сату очрагында.

Башкарма комитет үз инициативасы белән, шулай ук комиссия тәкъдиме белән конкурс шартларының үтәлешен тикшерү өчен экспертларны һәм консультантларны җәлеп итәргә хокуклы.

Комиссия конкурс шартларының үтәлешен тулаем тикшерә.

Конкурс шартларының үтәлеше турында җыелма (йомгаклау) хисапны карау нәтиҗәләре буенча конкурс шартларының үтәлешен контрольдә тоту комиссиясе конкурста җиңүче тарафыннан конкурс шартларын үтәү турында акт төзи. Әлеге актка җыелма (йомгаклау) хисап мәгълүматларын тикшерү эшендә катнашкан комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имза салына. Конкурста җиңүченең конкурс шартларын үтәү буенча йөкләмәләре сатучы тарафыннан расланганнан алып, Башкарма комитет җитәкчесе исеменнән комиссия тарафыннан әлеге акт имзаланганнан соң тулысынча үтәлгән дип санала.

Конкурс шартларын үтәү турында комиссия актында мәҗбүри рәвештә түбәндәгеләр чагылдырылырга тиеш:

- актның номеры, аны төзү датасы, урыны;
комиссия составы;
- җәлеп ителгән экспертлар һәм консультантлар составы (аларны җәлеп иткән очракта);
- конкурс шартлары;
- әлеге шартларның үтәлешен раслаучы документлар исемлеге;
- экспертларның, консультантларның бәяләмәләре (аларны җәлеп иткән очракта), җиңүче тарафыннан конкурс шартларын үтәүне тану мәсьәләсе буенча комиссия нәтиҗәләре һәм тәкъдимнәре.

3.8. Конкурста җиңүче тарафыннан аның шартларын үтәмәгән, шулай ук аларны тиешенчә үтәмәгән очракта, шул исәптән мондый шартларны үтәүнең арадаш яки ахыргы срокларын һәм аларны үтәү күләмен бозган очракта, муниципаль мөлкәтне сату-алу шартнамәсе яклар килешүе буенча яки, бер үк вакытта сатып алучыдан неустойканы түләтеп, суд тәртибендә өзелә.